**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О физической культуре и спорте»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
21 марта 2017 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 8 октября 2008 года № 99-ЗРТ «О физической культуре и спорте» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2008, № 10 (I часть); 2010, № 6 (I часть); 2011, № 5; 2012, № 7 (I часть); № 12 (II часть); 2013, № 6 (II часть); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II часть); 2015, № 3, № 7 (I часть), № 10 (I часть), № 11 (I часть); 2016, № 3, № 10) следующие изменения:

1) в статье 5:

а) пункт 1 изложить в следующей редакции:

«1) физкультурно-спортивные организации, в том числе физкультурно-спортивные общества, спортивно-технические общества, спортивные клубы (включая профессиональные спортивные клубы, физкультурно-спортивные клубы), объединения физкультурно-спортивных клубов, центры спортивной подготовки, профессиональные спортивные лиги, студенческие спортивные лиги, а также общественно-государственные организации, организующие соревнования по военно-прикладным и служебно-прикладным видам спорта;»;

б) дополнить пунктом $6^1$ следующего содержания:

«$6^1$) спортивные агенты;»;

2) часть 3 статьи 11 дополнить словами «в виде физкультурно-спортивных клубов по месту жительства, работы, школьных спортивных клубов, студенческих спортивных клубов, профессиональных спортивных клубов и иных спортивных клубов»;

3) дополнить статьей $11^1$ следующего содержания:

«Статья 11[1]. **Особенности регулирования деятельности в области профессионального спорта**

Особенности регулирования деятельности в области профессионального спорта устанавливаются Федеральным законом.»;

4) в части 14 статьи 12 первое предложение изложить в следующей редакции: «Международные спортивные мероприятия, в отношении которых возникают обязательства Российской Федерации, проводятся на территории Республики Татарстан только при условии согласования решений об их проведении с общероссийскими спортивными федерациями по соответствующим видам спорта, с органами исполнительной власти Республики Татарстан и с федеральным органом исполнительной власти в области физической культуры и спорта.», второе предложение после слов «на территории Республики Татарстан» дополнить словом «таких»;

5) в статье 14:

а) часть 2 после слов «порядок присвоения» дополнить словами «, лишения, восстановления»;

б) часть 3 после слов «Порядок присвоения» дополнить словами «, лишения, восстановления»;

в) часть 4 после слов «присваиваются физкультурно-спортивными организациями» дополнить словами «, организациями, осуществляющими спортивную подготовку, образовательными организациями, осуществляющими деятельность в области физической культуры и спорта,»;

6) статью 17 изложить в следующей редакции:

«Статья 17. **Предотвращение допинга в спорте и борьба с ним**

1. Предотвращение допинга в спорте и борьба с ним осуществляются в соответствии с федеральным законодательством.
2. Уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан в области физической культуры и спорта определяет должностное лицо, ответственное за организацию работы по предотвращению допинга в спорте и борьбе с ним во взаимодействии с российской антидопинговой организацией, федеральным органом исполнительной власти в области физической культуры и спорта, федеральным органом исполнительной власти, уполномоченным на медико-биологическое и медицинское обеспечение спортсменов спортивных сборных команд Российской Федерации.
3. Уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан в сфере охраны здоровья определяет должностное лицо, ответственное за организацию работы по предотвращению допинга в спорте и борьбе с ним во взаимодействии с российской антидопинговой организацией и федеральным органом исполнительной власти в области физической культуры и спорта.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
05 апреля 2017 года
№ 13-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Физик культура һәм спорт турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 21 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:
а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1) физкультура-спорт оешмалары, шул исәптән физкультура-спорт җәмгыятьләре, спорт-техника җәмгыятьләре, спорт клублары (һөнәри спорт клубларын, физкультура-спорт клубларын кертеп), физкультура-спорт клублары берләшмәләре, спорт әзерлеге үзәкләре, һөнәри спорт лигалары, студентлар спорт лигалары, шулай ук хәрби хезмәт һәм хезмәт спорт төрләре буенча ярышлар оештыручы иҗтимагый-дәүләти оешмалар;»;
б) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пункт өстәргә:
«$6^1$) спорт агентлары;»;

2) 11 статьяның 3 өлешендә «спорт клублары» сүзләреннән соң «яшәү урыны, эш урыны буенча физкультура-спорт клублары, мәктәп спорт клублары, студентлар спорт клублары, һөнәри спорт клублары һәм бүтән спорт клублары рәвешендә» сүзләрен өстәргә;

3) түбәндәге эчтәлекле $11^1$ статья өстәргә:

«$11^1$ статья. **Һөнәри спорт өлкәсендә эшчәнлекне җайга салу үзенчәлекләре**

Һөнәри спорт өлкәсендә эшчәнлекне җайга салу үзенчәлекләре Федераль законда билгеләнә.»;

4) 12 статьяның 14 өлешендә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Россия Федерациясе йөкләмәләре барлыкка килә торган халыкара спорт чаралары Татарстан Республикасы территориясендә бары тик аларны үткәрү турындагы карарларны тиешле спорт төрләре буенча гомумроссия спорт федерацияләре, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм физик культура һәм спорт өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы белән килештергәннән соң гына үткәрелә.», икенче җөмләдә «Татарстан Республикасы территориясендә» сүзләреннән соң «мондый» сүзен өстәргә;

5) 14 статьяда:

а) 2 өлештә «спорт разрядлары бирү тәртибе» сүзләрен «спорт разрядлары бирү, алардан мәхрүм итү һәм аларны кире кайтару тәртибе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «квалификация категорияләрен бирү тәртибе» сүзләрен «квалификация категорияләре бирү, алардан мәхрүм итү һәм аларны кире кайтару тәртибе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 өлештә «физкультура-спорт оешмалары» сүзләреннән соң «, спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар, физик культура һәм спорт өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары» сүзләрен өстәргә;

6) 17 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17 статья. **Спортта допинг куллануны булдырмау һәм аңа каршы көрәш**

1. Спортта допинг куллануны булдырмау һәм аңа каршы көрәш федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең физик культура һәм спорт өлкәсендә вәкаләтле органы спортта допинг куллануны булдырмау һәм аңа каршы көрәш буенча эш оештыру өчен җаваплы вазыйфаи затны Россия допингка каршы оешмасы, физик культура һәм спорт өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы, Россия Федерациясенең җыелма спорт командалары спортчыларын медик-биологик һәм медицина ягыннан тәэмин итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы белән хезмәттәшлектә билгели.

3. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтле органы спортта допинг куллануны булдырмау һәм аңа каршы көрәш буенча эш оештыру өчен җаваплы вазыйфаи затны Россия допингка каршы оешмасы һәм физик культура һәм спорт өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы белән хезмәттәшлектә билгели.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 05 апрель
№ 13-ТРЗ